ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 124

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

"12" 07 2022 ___ ел.

2022 елның 1 яртыеллыгы өчен коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан түләү күләмен үзгәртүдәге чикләүләрне үтәү буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап раслау хакында

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә боерык бирәм:

1. 2022 елның 1 яртыеллыгы өчен гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләргә кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап (кушымтада бирелә) расларга.
2. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүләрнең нигезле булу-булмавын тикшерү бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы"нда (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгару өчен юлларга.
3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары С.В.Зәһидуллинага йөкләргә.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасының
Дәүләт торак инспекциясенең
12.07.2022 №124 боерыгы
белән расланды

**2022 елның 1 яртыеллыгы өчен гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләргә кертелә торган түләү күләмен үзгәртү чикләмәләрен саклау буенча дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле нәтиҗәләре турында хисап**

Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртү индексларын формалаштыру нигезләре, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүдәге чикләүләрне үтәүгә карата дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле гамәлгә ашырыла.

2022 елның беренче яртыеллыгында үткәрелгән планлы тикшерү барышында муниципаль берәмлекләрдә коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын арттыру фактлары (алга таба – чик индекслар) ачыкланмады.

2022 елның беренче яртыеллыгында чик индексларны арттыру фактларына карата ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан планнан тыш тикшерүләр үткәрелмәде, әлеге тикшерүләрне үткәрү өчен нигезләр булмады.